**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең вазыйфалар буенча составына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре турында» 2017 елның 11 августындагы ПУ-698 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 9 февралендәге ПУ-93 номерлы һәм 2019 елның 15 июнендәге ПУ-350 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең вазыйфалар буенча составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры;»;

б) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты үзәге башлыгы – табиб-методисты (хәрби-табиблык экспертизасы);»;

в) түбәндәге эчтәлекле унөченче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең лицензия-рөхсәт бирү эше үзәге башлыгы урынбасары.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 11 август
№ ПУ-474

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ